СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район,
422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш
авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Ташкичү авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 21 » декабрь 2018 ел** **№ 23**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясына таянып, гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Ташкичү авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Ташкичү авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халык тыңлаулары халык, Ташкичү авыл җирлеге Советы (алга таба - Совет), Ташкичү авыл җирлеге башлыгы (алга таба - башлык) яисә контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә.

2) 5 статьяның 1 өлешендәге 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташкичү авыл җирлеге башлыгы яки контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә торган гавами тыңлаулар Ташкичү авыл җирлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә».

2. Әлеге карарны Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Фәйзуллин

СОВЕТ ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ